ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫСӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕСЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда Тел. 3-28-70

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«13» март 2020 г. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 июлендә 12 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге территориясендә коррупциягә каршы мониторингны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 04.05.2006 елдагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2014 елның 12 июнендә кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге территориясендә коррупциягә каршы мониторингны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2017 елның 20 июлендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында:

1. 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә

«1.2. Коррупциягә каршы мониторинг - коррупцияне күзәтү, анализлау һәм фаразлау, аны күрү өчен шартлар, коррупциягә каршы тору һәм коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча чаралар, шул исәптән аларның социаль диагностикасы, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Югары Сәрдә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Хөснетдинов